# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

# Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карары

Югары Стәрле авылы №175-106 «19 » май 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Кушымта итеп бирелгән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрьдә 47 номерлы карары «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38, 13.11.2018 №117-73, 04.02.2019 №125-79) карарлар редакциясендә) хупларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрьдә 47 номерлы карары (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38, 13.11.2018 №117-73,04.02.2019 №125-79) карарлар редакциясендә белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты – 2020 елның 28 маеннан 2020 елның 30 июненә кадәр;
- үткәрү урыны – Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г йорт;
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 30 июненә кадәр- Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г йорт,

Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

-Сабирҗанова Л.С– Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы;

-Идиятова Л.Р. – Югары Стәрле авыл җирлеге Советының № 7округ депутаты;

-Хасаншин И.С. – Югары Стәрле авыл җирлеге Советының № 4 округ депутаты;

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрьдә 47 номерлы карары (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38, 13.11.2018 №117-73, 04.02.2019 №125-79) карарлар редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2020 елның 25 маеннан да соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С.Сабирҗанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл Советының 2020 елның 19 маендагы 175-106 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карары**

Югары Стәрле авылы №175-106 __ ______ 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябрьдә 47 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38, 13.11.2018 №117-73карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 12 октябрьдә 47 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (06.09.2013 №66, 20.03.2014 №87, 22.08.2014 №107, 04.09.2017 №61-38, 13.11.2018 №117-73 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.11.13 пунктта:

а) «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.2. 2.11.16 пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.18 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.18. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.